| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — БОЕРЫК

02.06.2020 — № 332

Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 11.03.2013 ел, № 162 карары белән расланган керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт Кодексының 275 статьясы, Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат һәм Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 11 мартындагы 162 номерлы карары белән расланган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 3 абзацында «ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән срокларда ел саен» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Дуслык» («Дуслык», «Туслах») газетасында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе Ф.Ю. Терентьевка йөкләргә(килешү буенча).

Җитәкче — Л.Н. Маняпов